ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 28

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«21» 01 2019 г.

2018 ел өчен коммуналь хезмәтләргә гражданнардан
кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен
үтәү буенча дәүләт торак күзәтчелегенең һәм
лицензия контроленең нәтиҗәләре турында хисап
раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләргә гражданнардан кертелә торган түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру нигезләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. 2018 ел өчен коммуналь хезмәтләргә гражданнардан кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен үтәү буенча дәүләт торак күзәтчелегенең һәм лицензия контроленең нәтиҗәләре турында хисап (кушымтада бирелә) расларга.

2. ТКХ өчен түләүләрнең нигезле булу-булмавын тикшерү бүлегенә әлеге боерыкны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары С.В.Заһидуллинга йөкләргә.

Башлык С.А.Крайнов

Кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2019 елның 21 гыйнварындагы 28 номерлы боерыгы белән расланды

**2018 ел өчен коммуналь хезмәтләргә гражданнардан кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен үтәү буенча дәүләт торак күзәтчелегенең һәм лицензия контроленең нәтиҗәләре турында хисап**

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләргә гражданнардан кертелә торган түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру нигезләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан коммуналь хезмәтләргә гражданнардан кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен үтәү буенча дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле гамәлгә ашырыла.

2018 ел өчен, уздырылган планлы тикшерүләр барышында, муниципаль берәмлекләрдә коммуналь хезмәтләргә гражданнардан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик дәрәҗә (иң зур) индексларын (алга таба – чик дәрәҗә индекслар) арттыру фактлары ачыкланмады.

2018 ел өчен Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең тарафыннан чик дәрәҗә индексларны арттыру фактларының булу-булмавы предметына карата планнан тыш тикшерүләр күрсәтелгән тикшерүләрне уздыру нигезләре булмауга бәйле рәвештә үткәрелмәде.